ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2022 Казан ш. №414-3/тко-2022

«Саба районы Шәмәрдән ТКХ КҖП» ачык акционерлык җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2020 №568-26/тко-2020 карарында билгеләнгән озак сроклы чик тарифларга 2023 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Житештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 15 ноябрендәге 36-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә, 2023-2025 елларга каты коммуналь калдыкларны күмүгә озак сроклы чик тарифларга үзгәреш кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Саба районы Шәмәрдән ТКХ КҖП» ачык акционерлык җәмгыятенә каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2021-2025 елларга чик дәрәҗә тарифлар билгеләү турында» 18.12.2020 №568-26/тко-2020 карарына (Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 24.11.2021 №371-33/тко-2021 карары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карар белән үзгәреш кертелгән 2023 елга чик тариф 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Саба районы Шәмәрдән ТКХ КҖП» ачык акционерлык җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2020 №568-26/тко-2020 карарында билгеләнгән озак сроклы чик тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында» 24.11.2021 №371-33/тко-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2020 №568-26/тко-2020 карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.11.2022 №414-3/тко-2022 карары
редакциясендә) 1 нче кушымта

## «Саба районы Шәмәрдән ТКХ КҖП» ачык акционерлык җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2021 – 2025 елларга чик тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | | 2022 ел | | 2023 ел | 2024 ел | | 2025 ел | |
| | | 1 гыйнвар-дан | 1 июль-дән | 1 гыйн-вардан | 1 июль-дән | | 1 гыйн-вардан | 1 июль-дән | 1 гыйн-вардан | 1 июль-дән |
| | Саба муниципаль районы | | | | | | | | | |
| 1 | «Саба районы Шәмәрдән ТКХ КҖП» ачык акционерлык җәмгыяте* | 109,99 | 145,15 | 131,40 | 131,40 | 133,47 | 133,47 | 145,13 | 145,13 | 145,71 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2020 №568-26/тко-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 №414-3/тко-2022 карары редакциясендә) 2 нче кушымта

Каты коммуналь калдыкларны күмү буенча «Саба районы Шәмәрдән ТКХ КҖП» ачык акционерлык җәмгыяте өчен 2021 – 2025 елларга чик дәрәҗә тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрлары

| т/с | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен хәл итүче оешма исеме | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма чыгымы |
| | | | мең сум | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Саба торак-коммуналь хуҗалыгының Шәмәрдән күп тармаклы җитештерү предприятиесе» акционерлык җәмгыяте | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны күмү | 2021 | 4233,78 | 1 | 0 | 0 |
| | | 2022 | x | 1 | 0 | 0 |
| | | 2023 | x | 1 | 0 | 0 |
| | | 2024 | x | 1 | 0 | 0 |
| | | 2025 | x | 1 | 0 | 0 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге